РАИЛ ШАКИРОВ



# ДЕПУТАТ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ




# ДЕПУТАТ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

*Шигырьләр һәм поэма*

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1963

С(тат.)2
Ш17

* * *
Редакторы *Х. Камалов*
Художнигы *С. Кульбака*
* * *

ОЛЫ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН



**ЗАЛДА — МЕҢ КҮЗ**

Залда — мең күз,
Ә сәхнәдә —
Дөм сукыр ир уйный баянда.
Сөйләп бетмәс,
Телнең көче җитмәс
Әрнетерлек хисләр бар анда.

Җир шарына афәт алып килгән
Фашизмга каршы баскан ир,
Дөм караңгы зинданнарны җимереп,
Миллионнарның күзен ачкан ир,
Җиңеп кайткан.
Ләкин күрәлмәгән
гаиләсенең
Шатлык нуры тулган йөзләрен,
Төрмә хуҗалары — инквизитор
Чокып алган үткен күзләрен.